# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **23.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Вахитов авыл җирлегенэ
керүче Җину бистэсе 2020 ел үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә халык җыены карар бирэ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җинү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш .
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Җиңү бистәсендә урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Җиңү бистәсендә юлларны кардан чистарту;
- Җинү бистәсендә җәйге чорда территорияне чабу;
- юлларның чокырларын ремонтлау Яшел ур. Җиңү бистәсе;
- Җинү бистәсендә бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Җину бистэсе, Үзэк ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: Бухарова И.Б.